ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

18 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Татар Карамалысы авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Татар Карамалысы авылы территориясендә I группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешелэрдэн (80 яшькә җиткән ) һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Татар Карамалысы авылында коры агачлар һәм куаклар кисү;

2) Татар Карамалысы авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (яктырткычлар сатып алу, урнаштыру)

3) Татар Карамалысы авылы өчен урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр сатып алу;

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Гафиятуллин